# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге Дачный торак пунктынла халык җыены нәтиҗәләре турында

2020 елның 27 ноябреннән                                                                 № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 6 ноябрендә 19 сәгать 00 минутта, 2020 елның 20 ноябрендә 19 сәгать 00 минутта, 2020 елның 24 ноябрендә 19 сәгать 00 минутта уздырылган “Сез, 2021 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дачный авыл җирлеге Дачный авылы территориясендә балигъ булган даими яшәү урыны буенча теркәлгән, 80 яшьтән өлкәнрәк затлардан кала, 500 (биш йөз)сум күләмендә үзәра салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” дигән мәсьәләгә буенча халык җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

1) Дачный авылы эчендэге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, вак таш салу, асфальт кисем сатып алу, асфальт кисем салу, шартнамәләр буенча эшләр өчен түләү).

2) Дачный авылында балалар мәйданчыгын урнаштыру (балалар мәйданчыгы сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү).

3) Дачный авылы зиратына илтә торган юл салу. (вак таш сатып алу, вак таш салу, территорияне планлаштыру, ком сатып алу, ком салу, килешүләр буенча эшләр өчен түләү).

4) Дачный авылындагы урам яктырту челтәрләрен ремонтлау. (яктырткычлар сатып алу, урам яктырткычлары сатып алу, килешүләр буенча эшләр өчен түләү).

5) Дачный авылындагы агачларны кисү (килешү буенча эшләр өчен түләү, зур габаритлы чүп-чар чыгару).»

«РИЗА»                                                  «КАРШЫ»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә халык җыенында катнашучы 561(биш йөз алтмыш бер) кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан халык саны, 337 (өч йөз утыз җиде) кеше, бу 60%ны тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

“РИЗА” позициясе өчен халык жыенында 333 (өч йөз утыз өч) катнашучы тавыш бирде;

“КАРШЫ” позициясе өчен жыенда катнашучы 4 (дүрт) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районыны Дачный авыл җирлеге Дачный торак пунктында халык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дачный авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган 80 яшьтән өлкәнрәк затлардан тыш кешедән 2021 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.

3. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләргне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлтергә:

1) Дачный авылы эчендэге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, вак таш салу, асфальт кисем сатып алу, асфальт кисем салу, шартнамәләр буенча эшләр өчен түләү).

2) Дачный авылында балалар мәйданчыгын урнаштыру (балалар мәйданчыгы сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү).

3) Дачный авылы зиратына илтә торган юл салу. (вак таш сатып алу, вак таш салу, территорияне планлаштыру, ком сатып алу, ком салу, килешүләр буенча эшләр өчен түләү).

4) Дачный авылындагы урам яктырту челтәрләрен ремонтлау. (яктырткычлар сатып алу, урам яктырткычлары сатып алу, килешүләр буенча эшләр өчен түләү).

5) Дачный авылындагы агачларны кисү (килешү буенча эшләр өчен түләү, зур габаритлы чүп-чар чыгару)

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче Р.А.Жильцов